**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ**

422750, село Большая Атня, улица Советская, дом 38

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОН СОВЕТЫ**

422750, Олы Әтнә авылы, Совет урамы., 38нче йорт

Тел.: 8(84369)21004, факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«14» декабрь 2024 ел № 247

**2025 елга һәм 2026 - 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы бюджеты**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Әтнэ муниципаль районында бюджет процессы турындагы Нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Әтнә район Советы карар кылды:

**1 статья.**

1. 2025 елга Татарстан Республикасы Әтнэ муниципаль районы бюджетының теп характеристикаларын расларга:

а) Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләме 724344,2 мең сум күләмендә.;

б) Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 724344,2 мең сум күләмендә;

в) Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы бюджеты кытлыгы 0 мең сум.

2. 2026 елга һәм 2027 елга Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы бюджетының төп характеристикаларын расларга:

а) Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләме 2026 елга 767712,5 мең сум һәм 2027 елга 813752,4 мең сум күләмендә;

б) Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 2026 елга 767712,5 мең сум, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 9277,9 мең сум һәм 2027 елга 813752,4 мең сум, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 19186,9 мең сум;

в) Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы бюджеты кытлыгы 2026 елга 0 мең сум һәм 2027 елга 0 мең сум күләмендә.

3. 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә расларга.

**2 статья**

1. 2026 елның 1 гыйнварына Әтнә муниципаль районы муниципаль эчке бурычының югары чиген 0,0 мең сум күләмендә, шул исәптән Әтнә муниципаль районы муниципаль гарантияләре буенча Әтнә муниципаль районы муниципаль эчке бурычының югары чиген нульле Россия Федерациясе валютасында расларга.
2. 2027 елның 1 гыйнварына Әтнә муниципаль районы муниципаль эчке бурычының югары чиген 0,0 мең сум күләмендә, шул исәптән Әтнә муниципаль районы муниципаль гарантияләре буенча Әтнә муниципаль районы муниципаль эчке бурычының югары чиген нульле Россия Федерациясе валютасында расларга.
3. 2028 елның 1 гыйнварына Әтнә муниципаль районы муниципаль эчке бурычының югары чиген 0,0 мең сум күләмендә, шул исәптән Әтнә муниципаль районы муниципаль гарантияләре буенча Әтнә муниципаль районы муниципаль эчке бурычының югары чиген нульле Россия Федерациясе валютасында расларга.

**3 статья**

Әтнә муниципаль районы бюджетында 2025 елга һәм 2026 һәм 2027 еллар план чорына Әтнә муниципаль районы бюджеты керемнәренең фаразлана торган күләмнәрен әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә исәпкә алырга.

**4 статья**

1. 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Әтнә муниципаль районы бюджетының бюджет ассигнованиеләрен бюджет чыгымнары классификациясенең бүлекләре һәм бүлекчәләре, максатчан статьялары һәм чыгымнар төрләре буенча бүлүне әлеге карарга 3 нче кушымта нигезендә расларга.
2. 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Әтнә муниципаль районы бюджеты чыгымнарының ведомство структурасын әлеге карарга 4 нче кушымта нигезендә расларга.
3. Әтнә муниципаль районы бюджетының бюджет ассигнованиеләрен 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына бюджетлар чыгымнары классификациясенең максатчан статьялары (Әтнә муниципаль районы муниципаль программалары һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре, бүлекләре, бүлекчәләре буенча бүлүне әлеге карарга 5 нче кушымта нигезендә расларга.
4. Әтнә муниципаль районы бюджетының 2025 елга гавами норматив йөкләмәләрне үтәүгә җибәрелә торган бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен 6747,5 мең сум күләмендә, 2026 елга 6911,7 мең сум күләмендә һәм 2027 елга 7085,5 мең сум күләмендә расларга.

**5 статья**

1. Әтнә муниципаль районы бюджетына җирлек бюджетларыннан ял итүне оештыру һәм җирлек халкын мәдәният оешмасы хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыруга һәм Әтнә муниципаль районында күпфатирлы торак йортларга капиталь ремонт ясау вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга, 2025 елда төзелгән килешүләр нигезендә һәм 2026 һәм 2027 елларның план чорына туры китереп, 40412,0 мең сум күләмендә тапшырыла торган башка бюджетара трансфертлар күләмен әлеге карарга 6 нчы кушымта нигезендә бүлүгә таянып расларга.

2. 2025 елда һәм 2026 һәм 2027 еллар план чорында Әтнә муниципаль районы бюджетына әлеге статьяда каралган җирлекләр бюджетларыннан бюджетара трансфертлар күчерү ай саен тигез өлешләрдә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

**6 статья**

1. Җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр күләмен әлеге карарга 7 нче кушымта нигезендә бүлеп расларга:

2025 елга 73277,4 мең сум күләмендә;

2026 елга 77463,8 мең сум күләмендә;

2027 елга 81783,9 мең сум күләмендә.

**7 статья**

Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга авыл җирлекләре бюджетларына субвенцияләр күләмен әлеге карарга 8 нче кушымта нигезендә расларга:

2025 елга 2470,2 мең сум күләмендә;

2026 елга 2701,7 мең сум күләмендә;

2027 елга 2798,7 мең сум күләмендә.

**8 статья**

Татарстан Республикасы бюджетыннан алына торган бюджетара трансфертларны Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы бюджетында 2025 елда 460435,3 мең сум күләмендә, 2026 елда 489508,2 мең сум күләмендә, 2027 елда 519901,6 мең сум күләмендә исәпкә алырга, әлеге карарга 9 нчы кушымта нигезендә бүлеп бирергә.

**9 статья**

2025 елга Әтнә муниципаль районы Юллар фондының бюджет ассигнованиеләре күләмен 11415,9 мең сум күләмендә, 2026 елга 11833,3 мең сум һәм 2027 елга 12201,3 мең сум күләмендә расларга Һәм аларны тиешенчә 2025, 2026 һәм 2027 елларга Әтнә муниципаль районының гомуми файдаланудагы юлларында юл эшләре программасы чараларын гамәлгә ашыруга җибәрергә.

**10 статья**

Әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясаган өчен түләүдән, әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән файдалану өлкәсендә административ хокук бозулар өчен административ штрафлардан, мәҗбүри таләпләрне бозулар аркасында әйләнә-тирә мохиткә, шул исәптән су объектларына китерелгән зыянны каплау турындагы дәгъвалар буенча түләүләрдән, шулай ук түләнә торган түләүләрдән Татарстан Республикасы бюджетына күчерелгән салым булмаган керемнәр әйләнә-тирә мохиткә, шул исәптән су объектларына, мәҗбүри таләпләрне бозулар аркасында китерелгән зыянны иркле рәвештә каплаганда, әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыян объектларын ачыклауга һәм (яисә) әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыянны бетерүне оештыруга, хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынтысын булдырмау һәм (яисә) киметү буенча башка чараларга җибәрелә, табигать мохитен саклауга һәм торгызуга, табигать

ресурсларыннан нәтиҗәле файдалануга һәм аларны торгызуга, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан раслана торган Татарстан Республикасы табигатьне саклау чаралары планы нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органы белән килештереп, экологик иминлекне тәэмин итүгә.

**11 статья**

1. Әтнә муниципаль районының җирле үзидарә органнары 2025 елда муниципаль хезмәткәрләр, шулай ук җирле үзидарә органнары һәм муниципаль казна учреждениеләре хезмәткәрләре санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуклы түгел.
2. Авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарына 2025 елда муниципаль хезмәткәрләр, шулай ук җирле үзидарә һәм муниципаль казна учреждениеләре хезмәткәрләре санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итмәскә киңәш итәргә.

**12 статья**

2025 елның 1 гыйнварына Әтнә муниципаль районы бюджеты акчаларының калган өлеше, әлеге муниципаль контрактларның шартлары нигезендә 2024 елда түләнергә тиешле товарлар кайтартуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә Әтнә муниципаль районы исеменнән төзелгән муниципаль контрактлар өчен түләүгә файдаланылмаган бюджет ассигнованиеләре суммасыннан артмаган күләмдә, 2025 елда, Әтнә муниципаль районы башкарма комитеты тиешле карар кабул иткән очракта, күрсәтелгән максатларга тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыруга җибәрелә.

**13 статья**

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Әтнә районы Казначылык Департаментының территориаль бүлеге төзелгән килешүләр нигезендә Әтнә муниципаль районы бюджетын үтәү буенча аерым функцияләрне башкара.

**14 статья**

1. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан уз көченә керә.
2. Әлеге карарны «Әтнә таңы» район газетасында бастырып чыгарырга һәм Әтнә муниципаль районының http://atnya.tatarstan.ru рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълуматының http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында урнаштырырга.

**15 статья**

Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Әтнә муниципаль районы Советының бюджетын формалаштыру, икътисадый һәм социаль-икътисадый үсешен фаразлау буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Рәисе Ф.М. Нуриев).

Әтнә муниципаль районы башлыгы –
Әтнә район Советы рәисе Г.Г.Хәкимов